
Бу кон 1990 елда ООН Генераль Ассамблея карары белән халыкара бәйрәме дип билгеләнгән. Ә Мордовиядә кvптәннән 1-31 октябрьдә ай буе олкәннәргә, мохтәрәм яшьтәге ватандашларыбызга социаль, хокук, медицина һәм башка олкәдәрдә ярдәм итv, игътибар һәм хормәт кvрсәтv гадәткә керде. Бәйрәм кысаларында котлаулар, концертлар оештыралар, кино һәм театрларнын ишекләре ачык булачак, экскурсияләрнен торлеләре vтәчәк; спорт ярышларында катнашырга момкинчелекләр тудыралар. Бу коннәрдә пенсионерлар, сугыш, тыл һәм хезмәт ветераннары яшәреп киткәндәй булалар, vткәннәрен искә тошерәләр, бергәләшеп аралашалар.

Традиция буенча ай буе башкалабыз Саранскта торледән-торле чаралар vтә. Мордовия Главабыз Владимир Волков ел саен Халыкара олкәннәр конена багышланган тантаналы очрашу оештыра. Бу кичәдә пенсионерлар, сугыш, тыл һәм хезмәт ветераннарына матур cvзләр әйтелә, бvләкләр тапшырыла, концерт программасы оештырыла. Быел очрашуларын башлады инде. Республикабыз районнарындагы татар авылларында да олыларны хормәтлиләр.
Темник районы районы Тархан урта мәктәбе жирлегендә ел саен октябрьдә, числосы әлегә билгеле тvгел, Авыл администрациясе белән мәктәп коллективы берлектә авылдагы барлык пенсионер очен бәйрәм vткәрәләр. Мәктәп директоры Халисә Сафиулла кызы Кугушева белән сойләшкәндә: “Октябь ае – гади ай тvгел, чонки октябрьдә олкәннәргә аерым хормәт кvрсәтергә тырышабыз. Ел саен без олыларыбызны олылап, Тархан гомуми урта белем бирv мәктәбендә Тархан авыл администрация хезмәткәрләре һәм мәдәни, мәктәп халкы белән бергә, концертлы чәй эчv vткәрәбез. Бу чара олкәннәребезгә бик ошый. Үзләре дә, оныкларынын матур концертын тынлагач, гармунга кушылып жырлыйлар, биючеләре дә табыла. Кvнелле vтә бәйрәм. Ел саен ООО “Тархановское” жәмгыятьчелеге бу бәйрәмгә булдыралган кадәр олеш кертә, ә топ авырлык Авыл администрациясенә тошә”.
Рузаевка районы Татар Пешләсе авылында да ел саен Олылар айлыгын зурлап vтькәрәләр. Мәктәп директоры Флора Әхмәтжан кызы Шамонова белән бу турыда аралашканда: “Мәдәният йортыбыз, мәктәп халкы белән бергә, ел саен зур концерт оештырабыз. 20 ветеран педагогларыбызга vткән ел тагы ике укытучыбыз – Рәисә

Ибрагим кызы Кашаева белән Шәфика Шикур кызы Неясова кушылдылар. Авыл администрациясе житәкчелегендә чәй эчv оештырыла. Быел, коне билгеле булмаса да, олыларыбызга бәйрәм оештырырбыз», - ди.
Олылар язмышы - Ил язмышынын бер чаткысы. Хезмәт һәм сугыш ветераннарыбыз - безнен тарих, байлык, горурлык. Олыларыбызны ешрак искә алыйк, яхшылык эшләп олгерик.

**Н.Хәлил**